

Быел жиләк күп. Яз азагында тау битләре ап-ак чәчәккә күмелгәч үк өмет уяткан иде инде ул. Чәчәкләренә һәм бореләренә караганда, әле алга таба бер айлап жыячакбыз без бу жиләкне. Бакчадагы виктория, каен жиләге белән бергә урман-кырлардагысын жыябыз. Жиләкне үрмәләп тә, аунап та, ятып та жыя халык. Бу бит үзенә күрә бер рәхәтлек.      – Жиләк жыеп, ой салып яки машина алып буламы? – дип кызыксындым. – Анын кадәр үк зурдан кубып булмый. Әмма бик тырышсан, конгә 5-6 мен сумлык табыш алырга момкин. Күп дигәндә, 10 менлек саткан бар. Заказлар күп, жыеп кына олгер. Кем алдан сорый, беренче чиләк шуна эләгә. Элек юл буена чыгып сатсак, хәзер ойгә килеп алалар, – дип сойләгән Татарстаннын Балык Бистәсендәге Казаклар авылында яшәүче Сәрия Шәрәфиева “Матбугат” корреспондентына.
Мордовиядә дә жиләк сатып байтак мал табулары турында Саранскнын Светотехстрой районы базарында сойләделәр, фамилияләрен әйтергә теләмәсәләр дә. Ялкауланма гына, диләр.
Былтыр каен, жир жиләге аз булса, быел шулкадәр күп икән. Аны ерактан эзләп тә йорисе түгел, тик юл яннары поляналарга гына күз салырга ярамый. Урманнарнын чистарак, кырларнын юлдан ераграгында алар татлы да, файдалы да.
Кырларда зур-зур поляна тапкач, менә ичмасам жиләккә туясын! Конгә хәтта икешәр тапкыр барып, 20шәр литр жыеп кайтучылар бар. Ә Ләмберә районы “Пензятка авылы клубы” “Республикабыз халкы ижат Йорты” белән Вkontakte социаль челтәрендә оештырылган флешмобта менә шулай актив катнашалар. Фотода (сулдан унга) – Эльвира Касим кызы Монасыпова, Алина Наиль кызы Бикмаева, Юлия Ринат кызы Ашрятова. Эх, булдырганнар да инде чибәркәйләр! Чиләкләре молдерәмә тулы; фотодан ук эре, олгереп пешкән жиләкнен хуш исен тоярга була...
Рузаевка районы Татар Пешләсендә урман яны кырларына жиләккә еш йориләр. Сания ханым Саляева: “Мин таудагы жиләклеккә кичке сәгать 5тә менәм дә 7гә кадәр биш литрлы чиләгемне хуш исле жир жиләге белән тутырып алып кайтам”, - дип кичә генә әйтте аралашканда.

Кондәшлек дигән нәр- сәне дә белми авыл халкы. Әйдә, бергә жиләк жыеп кайтабыз дип, тирә-кvршеләрен, туган-тумачаларын, дусларын шәһәрдән кунакка чакыралар авылдагылар. Сатарга да, ашарга да житә. Жәй тик ятмасан, кыш буе жиләк ашыйсын. Кышка тоеп тә куялар, кайнатмасын да ясыйлар икән. Шул базар апаларынын берсе рецепты белән бvлеште. Бу эчемлек бvгенге эсседә коч ости, ди. Ярты стакан каен жиләгенә шикәр комы, сот салып, блендерда болгатып, коктейль ясап эчегез, дип кинәште. Бик файдалы, тимер кvп. Гемоглобины тvбән булган кешеләргә аеруча яхшы. Бик тиз хәл кертә. Аны эчкәч, арыганнар бетеп, тагын жиләккә барасы килә башлый, икән. Жир жиләге, виктория белән дә бик әйбәт була коктейль.
Бvген табигатьнен бик матур вакыты. Шулай да, ни кызганыч, жәйнен бер ае vтеп тә китте. Инде вируслы чирләр, анын белән бәйле чикләvләр тәмам бетеп, калган айларында рәхәткә иркенләп тиенергә язсын иде.

**Н.ХӘЛИЛ**